112

# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасының сайлау системасын камилләштерүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

I. Татарстан Республикасы Конституциясенә (Татарстан Югары Советы Жыелма басмасы, 1992 ел, №9-10; 1994 ел, № 11; Татарстан Дәүләт Советы Жыелма басмасы, 1995 ел, № 2-3, № 12; 1996 ел, № 11) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1 статья. 66 статьяның алтынчы өлешен төшереп калдырырга.

2 статья. 68 статьяга түбәндәге эчтәлектә өченче өлеш өстәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм халык депутатларының жирле Советларына сайлаулар башка вакытка күчерелергә мөмкин, әмма ул вакыт дүрт айдан да артмаска тиеш.».

3 статья. 70 статьяның өченче өлешендә «иректән мәхрүм итү урынында тотылган кешеләр» сүзләреннән соң «,шулай ук психиатрия хастаханәсендә ятып дәваланучы психик авыру гражданнар» сүзләрен төшереп калдырырга.

4 статья. 72 статьяның беренче өлешенә «Премьер-министрдан кала башка әгъзалары,» сүзләреннән соң «башкарма хакимият федераль органнарының Татарстан Республикасындагы территория органнары житәкчеләре» дигән сүзләрне өстәргә.

5 статья. 76 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«76 статья. Эш (уку, хезмәт итү) урыны һәм яшәү урыны буенча сайлаучылар җыелышлары, үзен үзе күрсәтү тәртибендә сайлаучылар, шулай ук законда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән сайлау берләшмәләре һәм сайлау блоклары халык депутатына кандидатлар күрсәтү хокукына ия булалар.».

6 статья. 78 статьяның соңгы җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Сайлау комиссияләрен оештыру һәм аларның эшчәнлеге тәртибе закон белән билгеләнә.».

7 статья. 79 статьяга «гарантияләнә» сүзе алдыннан «закон нигезендә» дигән сүзләрне өстәргә.

8 статья. 81 статьяның беренче өлешендә «бәхәсләрне» сүзеннән соң «югарырак сайлау комиссияләре йә» дигән сүзләрне өстәргә.

9 статья. 89 статьяның икенче өлешендәге 22 пунктында «Татарстан Республикасы Үзәк референдум комиссиясе составын раслау» сүзләрен төшереп калдырырга.

10 статья. 89 статьяның икенче өлешендәге 24 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24) Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе составын раслау;».

11 статья. 89 статьяның өченче өлешендә түбәндәге эчтәлектә 18 нче пункт өстәргә:

«18) Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе составын раслау.».

12 статья. 92 статьяның икенче өлешендә «халык депутатларын сайлаулар буенча» сүзләрен төшереп калдырырга.

13 статья. 94 статьяга «Татарстан Республикасы Прокуроры» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасының сайлау системасын камилләштерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе» дигән сүзләрне өстәргә.

14 статья. 101 статьяның беренче өлешендәге 2 пунктында «халык депутатларын сайлаулар буенча» сүзләрен төшереп калдырырга.

15 статья. 111 статьяның 7 пунктындагы «халык депутатларын сайлаулар буенча» сүзләрен төшереп калдырырга.

II. Әлеге Закон басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1999 елның 21 июле
№ 2304